КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 сентябрь г.Казань № 854

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, М.Җәлил урамы, 18 нче йорт адресы буенча «1941 елда хәрби-сәяси училищеда патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил укыган йорт» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, әлеге зоналар чикләрендә җирләрне файдалану режимнарын һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау зоналары турындагы нигезләмәне раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында кайбер нигезләмәләр үз көчен югалткан дип тану хакында» 2015 елның 12 сентябрендәге 972 номерлы карары, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, М.Җәлил урамы, 18 нче йорт адресы буенча «1941 елда хәрби-сәяси училищеда патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил укыган йорт» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, әлеге

зоналар чикләрендә җирләрне файдалану режимнарын һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне расларга.

2. Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә шәһәре, М.Җәлил урамы, 18 нче йорт адресы буенча «1941 елда хәрби-сәяси училищеда патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил укыган йорт» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары булу турындагы мәгълүматларны Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) буенча бердәм дәүләт реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин